ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.23 статья өстәргә:

«2.23 статья. **Тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюларны һәм (яисә) чикләүләрне үтәмәү**

Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюларны һәм (яисә) чикләүләрне үтәмәгән өчен –

гражданнарга – өч меңнән алып биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр административ штраф салына.»;

2) 7 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.11 статья өстәргә:

«7.11 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органы**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органы әлеге Кодексның 2.23 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән орган исеменнән административ хокук бозулар турындагы эшләрне Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе җитәкчесе, аның урынбасарлары, Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенең территориаль органнары башлыклары карый.»;

3) 8.1 статьяда:

а) 1 өлештә «7.10» саннарыннан соң «, 7.11» саннарын өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ өлеш өстәргә:

«$10^1$. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очраклардан тыш, әлеге Кодексның 2.23 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе һәм аның территориаль органнары структур бүлекчәләренең вазыйфаи затлары төзи.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 03 гыйнвар
№ 2-ТРЗ